РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 9 феврале** **Чистай шәһәре** **№6/2**

Татарстан Республикасы
Чистай шәһәр Советының
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районының«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау
шартнамәләре буенча аренда түләвен
кичектереп тору шартлары турындагы
нигезләмәне раслау турында»
2020 елның 13 маендагы 46/4 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карарының 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 13 маендагы 46/6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында, шулай ук дәүләт милке булган җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, аның турында мәгълүмат

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында йә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә торышы буенча бирелә.»;

1.2. 3 пунктта:

беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә;».

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә (Добронравова О.В.) йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов